



*“Пар канатларым – әти-әниемнең китап турында истәлекләре”*

*Татарстан Республикасында Гаилә елы уңаеннан, гаилә һәм мәктәп арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту, гаиләдә бергәләп китап уку культурасын, бала һәм ата-аналарны тәрбияләүдә китапханәнең рухи-әхлакый үзәк буларак ролен арттыру максатыннан 2024 елның 15 ноябрендә лицей китапханәсендә “Пар канатларым – әти-әниемнең китап турында истәлекләре” дигән чара узды. Кичәдә лицейның татар телендә аралашучы 1-4 сыйныф укучылары һәм аларның әниләре, лицей җитәкчеләре, укытучылары катнашты.*

*Очрашуда китапка кызыксынуның, укуга карашның, туган телгә мәхәббәтнең иң беренче гаиләдә тәрбияләнүе хакында мәгълүмат бирелде. Татар халкының борын-борыннан гыйлемле халык булуы, гаиләдә һәрчак китапның урыны түрдә булганлыгы искә алынды. Катнашучылар китапның кешенең акыл һәм күңел дөньясын кимсетмичә гасырлардан-гасырларга алып килүче һәм киләчәккә илтүче уңалмас рухи хәзинәләр казанышы булуын ассызыкладылар. Китапханә мөдире кунакларны татар әдәбиятының борынгы ядкяре, Идел буе Болгары дәүләтеннән калган бердәнбер әдәби әсәр – Кол Галинең «Кыйссаи Иосыф»” китабы белән таныштырды. 1982 елда нәшер ителгән китапның лицей өчен бик кадерле бүләк икәнлегеген әйтте.*

*Чарага килгән һәр әни үз баласына кечкенә вакытта үзе яратып укыган китабы хакында кызыклы мәгълүмат җиткерде. Кемдер өчен Гаяз Исхакый “Кәҗүл читек”, “Сөннәтче бабай” әсәрләре белән бик кадерле булса, кемнәрдер Абдулла Алишның “Куян кызы” хатирәләре белән яши икән!*

*Кичә ахырында гаилә белән бергәләп укуның ни дәрәҗәдә мөһим һәм кирәкле гамәл булуы ачыкланды. Кунаклар балалары белән бергә туган телебез – татар телендә китаплар укырга, шигырьләр өйрәнергә сүз биреп, алга таба да очрашып-аралашып, фикерләр белән уртаклашып торырга дип таралашты.*







